МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.07.2018 г.Казань № 560

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 3 августында теркәлде, № 4814

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасында үзгәрешләр булуга бәйле рәвештә һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын

биләүгә дәгъвалык итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелә торган, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 16 мартындагы 157 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 16 мартындагы 157 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 18 декабрендәге 929 номерлы.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр [signature] Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.07.2018 № 560 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) эшләр белән идарә итүчесе;

Министрлык бүлеге башлыгы;

муниципаль районда (шәһәр округында) Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе;

Министрлык бүлеге башлыгы урынбасары;

Министрлыкның сектор мөдире;

муниципаль районда (шәһәр округында) Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе урынбасары;

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфасы – министр ярдәмчесе;

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» һәм «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

3.1. юридик бүлектә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, алар буенча вазыйфаи бурычларны үтәү контроль һәм күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыруны күздә тота;

3.2. дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы белгеч;

3.3. мәгълүмат технологияләре, техник тәэминат һәм автоматлаштырылган системаларны эксплуатацияләү, мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.4. массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.5. хезмәтне планлаштыру, финанслау һәм түләү бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.6. контроль-ревизия эше бүлегендә – әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч, 1 разрядлы белгеч;

3.7. дәүләт сатып алулары бүлегендә – әйдәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.8. тармак программаларын үстерү һәм эшләү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.9. социаль ярдәм күрсәтү чаралары методологиясе бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.10. социаль регистрны формалаштыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.11. социаль ярдәм күрсәтү чараларына аудит бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.12. пенсиягә өстәмә түләү һәм эшләгән еллар өчен пенсия билгеләү һәм түләү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.13. социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.14. хезмәт базарын мониторинглау һәм дәүләт хезмәтләре бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.15. һөнәргә укыту һәм һөнәри юнәлеш бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.16. хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.17. чаралар уздыруны оештыру бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.18. эш башкару бүлегендә – әйдәп баручы белгеч;

3.19. социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.20. социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатына идарә итү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, әйдәп баручы белгеч-эксперт;

3.21. иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче;

3.22. административ-хуҗалык бүлегендә – 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.23. җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегендә – әйбәп баручы белгеч, 1 разрядлы өлкән белгеч;

3.24. халык белән эшләү секторында – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;

3.25. муниципаль районда (шәһәр округында) Министрлыкның территориаль органында – консультант, әйдәп баручы белгеч-эксперт.

---